**Яшәсен җирдә ТЫНЫЧЛЫК!**

Еллар үтә, һәр ел тарихта үзенең эзен калдыра. Еллар көннәрдән тора, ә һәр көн таң белән башлана. Урман эчендә урнашкан авылыбыз үз гомерендә күпме таңнар каршылаган!.. Һәр таң я шатлыклы, бәхетле көннең башлангычы була, я күңелләрне тетрәтерлек кайгы-хәсрәт алып килә. Ләкин таңга гына карап көннең нинди буласын алдан чамалап булмый. Кайвакыт, бигрәк тә җәйге аяз көннәрдә таңнар шундый матур булып ата ки, әйтерсең лә офыктан күтәрелеп килгән кояш нурлары бөтен дөньяга бәхет китерә, әйтерсең лә бу таң матурлыгы мәңгелек...

Менә шундый таңнарның берсе -1941 нче ел 22нче июнь. Якшәмбе көн. Кояш чыгарга иртәрәк әле. Кешеләр тыныч йокыда. Бөтен табигать сихри тынлыкка чумган. Кайдадыр еракта чут-чут итеп сандугач сайравы гына ишетелә. Шушы тынлыкны бозып, кинәт көнбатыштан самолетлар гөрелтесе ишетелә. Шомлы үкерү тавышы көчәйгәннән-көчәя бара, кешеләр ни булганын аңлап бетергәнче йөзләгән, меңләгән хәрби самолетлар тыныч шәһәрләр һәм авыллар өстенә бомбалар яудыра башлый. Күпкатлы йортлар гөрселдәп авалар, күккә тузан болыты күтәрелә, коточкыч янгын башлана. Дөньяның асты өскә килгәндәй була. Урамнарда, юлда очраган бөтен нәрсәне вата-сыта килүче свастикалы танклар, бала-чаганың, аналарның ачынып елаган тавышлары, кан, үлем...

Тиздән радио туган илебезгә фашистлар Германиясенең хыянәтчел һөҗүме турында куркыныч хәбәр тарата. Бөек Ватан сугышы менә шулай башлана. Һәркем өчен дә авыр сынау еллары башланып китә.

Авылыбызга сугыш башлану хәбәре шул ук көнне килеп ирешә. Яшьләрнең күбесе сугыш башлану хәбәрен ишетүгә, үзләрен фронтка җибәрүләрен сорап, военкоматка баралар. 1941нче елның 22 июнендә бер көн эчендә авылыбыздан шактый ир-егет сугышка китә. Авыл башына чыгып, хатыннар ирләрен, ваемсыз сабыйлар әтиләрен, яшь кызлар сөйгәннәрен фронтка озата. Берни аңламаган сабыйлар сугышның нинди куркыныч икәнлеген белмиләр шул әле.Тиздән, бик тиздән үзләренең ятим каласыларын да, балачаклары буразна арасында үтәчәген дә аңламый алар. Сугыш рәхимсез. “Әткәй, китмә!”- диеп елаган балалар инәлүен дә ишетми ул сугыш.

Авылым халкы аларны авылның иң калку урыныннан озатып кала. Озатучылар аларга бер теләк - дошманны тизрәк җиңеп кайтуны телиләр. Сылу егетләр, ир уртасы абыйлар изге Ватан өчен сугышка китә. Тылда калучыларга да җиңел булмый. Ләкин солдат әтиләрен, кардәш-туганнарын бөтен нәрсә белән тәэмин итеп тору өчен, станоклар артында торучылар да, колхоз басуларында алны-ялны белмичә эшләүчеләр дә хатын-кыз, карт-коралар, бала-чагалар була. Сыкранмый, сызланмый һәммәсен дә үз җилкәләрендә күтәрәләр алар.

Әйе, авылда карт –коры, хатын-кыз һәм балалар кала. Сабый чагын күрми, күпме михнәт, авыр хезмәт татый аның әле өлгереп тә җитмәгән иңнәре. Тормышны алып барырга кирәк: кырда игенен дә игәргә, ач-ялангач та

булмаска, сугышка төрле җылы киемнәр дә әзерләргә , гомер буе бетмәс кебек тоелган налогын да илтеп түләргә. Әтиләре, абыйлары сугыш кырында батырларча көрәшкәндә, тылда әниләр, сабый балалар үзләрен аямыйча эшлиләр.

Сугыш чоры балалары ачлыкны да, ялангачлыкны кичергәннәр. Авылыбызда мондый балалар саны шактый күп була.

Сугыш... Күпме сагыш, кайгы, күз яшьләре алып килдең син! Никадәр югалту, бәхетсезлек китердең тынычлык халкына. Син аның бәхетен урлап, рухын сындырырга, юк итәргә, колга әйләндерергә, кешеләрне тезләндереп, алар өстеннән явызларча хакимлек итәргә теләгәнсеңдер. Безнең илнең көчсез, әле ныгып җитмәгән булуыннан файдаланырга теләгәнсеңдер. Ләкин бер хакыйкатьне син аңламагансың. Безнең илебез яшь, көчсез булса да, аның горурланып сөйләрлек , курку белмәс, җиңелмәс батыр уллары, кызлары, шундый батыр йөрәкле балалар үстергән аналары бар. Безнең илебез зур сынаулар, авыр юллар, чиксез күп югалтулар белән җиңү таңын каршылады. Әйе, Җиңү исәпсез-хисапсыз корбаннар барәбәренә яуланды. 69 нче Җиңү язын каршыларга җыенабыз. Тагы күп дистә еллар үтәр. Буын арты буын алмашыр, ләкин Бөек Җиңү һәм шушы җиңүне яулап алган какшамас фронт һәм тыл каһарманнарының якты истәлеге халык күңелендә мәңге яшәр.

Мин дә, миллионнарча кешеләр кебек үк, сугыш теләмим. Кайвакыт уйланам. Хыялларым ак аргамактай еракларга оча... Илләребез имин, күкләребез һәрчак аяз булсын!.. Кабат сугыш афәтләрен күрергә язмасын!

Мин хәтерлим, июнь иртәсендә
Илгә кара кайгы килгәнен.
“ Сугыш!” дигән яман хәбәр белән
Ачы хәсрәтләрнең иңгәнен.

Т. Шәрипова.

1941-1945 нче еллар халкыбыз тарихына утлы-канлы хәрефләр белән язып куелган. Бөек Ватан сугышы. Аяусыз бәрелешләр, киселгән гомерләр, ятимнәрнең ачы күз яшьләре. Без яу кырында илебез азатлыгы өчен һәлак булган миллионлаган сугышчыларга, бүгенге көндә исән булып сугыш елларының истәлеген кадерләп саклаучы ветераннарга рәхмәтлебез. Ачлы-туклы көн-төн иген үстергән, үзләренең фидакарь хезмәтләре белән җиңү көнен якынайткан тыл хезмәтчәннәренең батырлыгы бервакытта да хәтеребездән җуелмас. Сугыш уты, сугыш җиле кагылган һәркем үзеннән соң килгән буыннарның рәхмәтенә һәм хөрмәтенә лаек.

Безгә, яшь буынга, татар язучысы Н.Дәүлинең “ Яшәү белән үлем арасын-да”әсәреннән алынган өзек белән мөрәҗәгать итәсем килә:” Яшь кеше! Әгәр син иртә белән тыныч йокыдан уянгач, тәрәзә төбендә ефәк яфраклы гөлләрнең чәчәк атуын күрсәң, әгәр син шул иртәдә өй каршындагы тирәкләрдә кошларның сайравын ишетсәң, бел - бу иртәнге шатлыкта сугышта үлеп калган солдатларның, фашист тоткынлыгында һәлак булган ватандашларыңның ялкынлы тормышы бар.

Әгәр син тыныч өйдә, иркен мәктәптә дәрес укып утырасың икән, бел - бу җиргә синең матур яшәвең өчен меңләгән солдатларның, меңләгән патриотларның, йөзләгән авылдашларыңның каннары түгелгән. Бу яшьлекнең кадерен бел, яшь кеше!”

Җиңү көнен якынайту өчен авылда калган яшүсмерләр һәм олы яшьтәгеләр барысын да эшлиләр. Ачлы-туклы булган килеш, аякларына чабаталар киеп басуларда печән чабалар. Көзләрен ашлыкларны чистартып амбарларга салалар, ә аннары атларга төяп, атлар җитешмәгәндә үзләре тартып дәүләткә тапшыралар. Район үзәгенә генә түгел, Казан шәһәренә һәм күрше районнарга да барганнар. Юлларда төрле хәлләргә дучар булганнар, салкыннарда өшеп кар бураннарында адашып та беткәннәр. Әмма, аларны бер нәрсә- уртак максат берләштергән, илгә файда китерү, сугышта җиңүгә үз көченңне кертү, җинүне тизләтү.

Җиңү көне! Өлкән буын аны якынайту өчен күпме кан койды! Күп газаплар, кайгы-хәсрәтләр китерде сугыш. Күпме арысландай егетләребез яу кырында ятып калды, күпме сылу кызлар ир назыннан мәхрүм булды. Зур корбаннар бәрәбәренә булса да Советлар Союзы Европаны фашизм тырнагыннан коткарып калды.

Иксез-чиксез галәмнән караганда, Җир шары бер ноктага сыядыр. Менә шушы ноктада кешеләр үзен үзе белә башлаганнан бирле гел сугыша, кан коя. Бүген Җир шарындагы тереклекне йөзәр, меңәр кат юк итәрлек атом-төш коралы, бактерологик кораллар бар. Тик шуны онытмыйк: бер материктан икенчесенә җибәрелгән бомба ахыр чиктә үзләрен дә юк итәчәк. Чөнки Җир шары никадәр зур булып тоелса да, ул шул кадәр үк кечкенә. Шулай булгач, безнең Ватан ул шулай ук башкалар өчен дә Ватан. Яшәсен җирдә ТЫНЫЧЛЫК!.



Без Җиңүнең 69 еллыгын каршыларга әзерләнәбез. Ә сугыш ветераннары һәм тыл батырлары көннән-көн кими бара. Аларга аз гына булса да ярдәмебез тисен иде. Аларга карата мәрхәмәтле, ярдәмчел булыйк. Безнең хәзерге матур, тыныч тормышыбыз өчен көрәшүчеләрне хөрмәт итик. Алар бит бу зур җиңүне үзләренең газиз гомерләре бәрабәренә яуладылар.

Авылыбызның күпме асыл ир-егетләрен йоткан ул рәхимсез сугыш. Киләчәктә илебез тыныч, күгебез аяз, әти-әниебез тигез, тормышлар матур булсын өчен без тарышып укып намуслы, чын кешеләр булып үсәргә тиешбез.

Сугышлар булмасын, булмасын! Туган илебез матур тормышта бәхетле яшик. Әйтерсең лә әбиемнең изге теләкләрен җиткерәләр:

Тәлгәш-тәлгәш зирек алкалары
Нәрсә әйтергә телиләр икән?
Тыныч илләрдә яшәгез,
Сугыш күрмәгез, - диләр микән.

Сугыш, сугыш... Кемнәрнең язмышына кагылмаган да, кемнәрнең башларына кайгы, күз яше, хәсрәт китермәгән ул. Кешелек дөньясы, сугышлардан ачы сабак алып җир йөзендә мәңге тынычлык, бәхет өчен көрәшергә тиеш.

Сугышлар беркайчанда булмасын иде. Гөрләп туйлар узсын, сабыйлар тусын, барысы да әтиле-әниле үссеннәр иде! Җирдә матурлык яшәсен! Бары матурлык кына дөньяны афәттән саклый.

# Яшәсен җирдә ТЫНЫЧЛЫК!

Урманасты Шонтала
урта мәктәбенең 7 сыйныф
укучысы Миндубаева Айзиләнең
эше.

2014 ел, 14 апрель